| ЛЕНИНОГОРСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.05.2019 №196

Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналашуы картасына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясына, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына таянып һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертү проекты буенча фикер алышу нәтиҗәләрен карап, Лениногорск шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Лениногорск шәһәр Советының 2013 елның 27 декабрендәге 121 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Җирдән файдалану һәм төзелешләр Кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зонасына Р-1 территориаль зонасын (рекреацион-ландшафт территорияләр зонасы) Д-1 (иҗтимагый эшлекле һәм коммерция билгеләнешендәге зона) территориаль зонасы өлешен үзгәртү буенча, Татарстан Республикасы, Лениногорск шәһәре, Вахитов урамындагы 16:51:010401:3717 номерлы җир участогына мөнәсәбәттә, сүәдә павильоны төзү буенча, картага үзгәрешләр кертергә.

2. Җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең шәһәр төзелеше зоналашуы картасына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә һәм яңартылган документларны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Россия Федерациясе территориаль планлаштыруның федераль геомәгълүмат системасында урнаштырырга (ФГИС ТП).

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://Leninogorsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Карар үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. Н. Карасевка йөкләргә.

Лениногорск шәһәре муниципаль
берәмлеге башлыгы, Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов